КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 5 август г.Казань № 646

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 28 март, 233 нче карары белән расланган Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 28 март, 233 нче карары белән расланган Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «квартал саен, тиешле финанс елында үткән кварталдан соң килүче айның 30ына кадәр,» сүзләрен «ай саен» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта «квартал» сүзен «ай» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин